**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР № 38**

**Димтамак ав.** **18 декабрь 2023 ел**

Димтамак авыл җирлеге Советының 2016 елның 31 мартындагы 7 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында»гы 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 23 июнендәге «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы»ның 50-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Димтамак авыл җирлеге Советының 2016 елның 31 мартындагы 7 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 8 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә һәм әлеге алыш-бирешләрне башкару чыганаклары хакында.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет»

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.



Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов